


## *Рафис Сәлимҗанов*

Рафис Сәлимҗанов 1952 елда Тукай районы Иштирәк авылында туа. 1975 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач, мәктәптә укыта, Зәй районы газетасы редакциясендә эшли. 1979 елдан бирле — Брежнев шәһәрендә.


---

# ВАКЫЙФ ДУС БЕЛӘН КҮРГӘННӘР

## Чыбык очы

— Болар — безнең чыбык очлары.

Башта апаларына кердек. Аннары абыйларына. Аннары җизнәләренә. Аннары җизнәләренең бажаларына. Аннары җизнәсенең бажасының апаларына. Хәзер — менә чыбык очларына.

Мондый сүзне мин беренче кат ишетә идем. Ни төсле була икән ул — чыбык очлары?

Капканы ачтык.

Вакыйф баскыч төбенә чаклы барды да, кул изәп, мине чакырды.

Килдем.

— Хәзер ишекне ачам да, алдан син керәсең,—ди Вакыйф.

Мондый хәлләргә беренче тапкыр гына юлыгу түгел. Кертеп җибәрә дә, үзе капкадан ук чыгып кача. Син өйгә барып керәсең... Өйдәгеләр сиңа карап тора, син аларга. Инде кире чыгып китеп булмый бит — телгә киләсең. Ә ул синең чыкканыңны урамның икенче ягында көтеп тора. Муенын кыса-кыса, бот чаба-чаба көлә.

— Юк,— дидем.— Синең чыбык очы, син беренче булып кер...

Вакыйф миңа карап тора. Борылып өйгә күз атып ала. Биек баскычлар, яхшы түбә, буялган тәрәзәләр... Боларда безгә кирәге булмый калмас. Ә безгә кирәге — конфет я шоколад ише берәр нәрсә инде.

Вакыйф ишекне ача. Мин аңа ияләм.

Өй эче. Башта күз ияләнмичәрәк тора. Өстәл тирәли алты-җиде кеше тезелеп утырган. Бала-чагасына чаклы. Зәңгәр чынаяклар белән сөтле чәй эчәләр.

— Нәрсә кирәк, балалар? — диде бер апа.

Мин Вакыйфның дәшкәнен көтәм. Ә ул башын игән, җебеп төшкән, тик тора. Тегеләр исә, иң бәләкәй кызга чаклы, чәй эчүдән туктадылар.

— Ни кирәк сезгә, балалар?

Болай торып булмый бит инде! Вакыйф ишеккә таба карап алды. Әһә, чыгып китәргә чамалый.

— Без...— Мин сүзгә керештем.— Безгә кирәгие...

— Ни кирәгие?

Мин өстәлгә карап алдым.

— Конфет...

Тынлык.

Апа урыныннан тора һәм шикәр савытыннан кәгазьле берничә конфет алып, икебезнең дә учка сала.

— Рәхмәт,— дип мыгырдана кызарган Вакыйф.

— Рәхмәт,— дим мин.

— Тукта, тукта,— ди өстәл янында утырган абзый кеше.— Шту-то берсе таныш бит боларның миңа... Әхмәтхан абзыйның Вакыйфы түгелме соң зурысы?

Абзый, урыныннан торып, безгә таба килә башлый.

Вакыйф чыгып йөгерә.

Мин аңа иярәм.

Тыкрыкка җиткәч кенә туктый Вакыйф.

— Нигә йөгердең син?

— Болар безнең чыбык очлары булып чыкмады бит,— дип сөйли башлый ул.— Болар бит Рифкать абыйларның өе булып чыкты. Узган ел ике баш көнбагышларын чәлгән идем мин аларның. Тагын бер күрсәм, сәнәк белән чәнчим дип, арттан кычкырып калганые... Уф! Ярый әле, ярый әле, сәнәкләре тышта ие!

**Тәгәрмәч**

Яз. Тау битләрендә чирәм төрткән вакыт. Бакча артындагы калкулыкта — бала-чага. Чирәмгә сызыклар сыза-сыза, шакмаклы уйныйлар.

Аста шаулап-гөрләп ташу ага.

Күзгә Вакыйф чалынды.

Кулын изи — мине чакыра. Абынасөртенә янына йөгердем.

— Тәгәрмәч кирәкме? — ди бу миңа.

— Кирәк,— дим.

— Киттек алай булгач,— ди.

Елга аша салынган басмага таба киттек.

— Әнә күрәсеңме тәгәрмәчне? — ди.

Яр буенда, басма астында ук, бозга чак кына эләгеп бер тәгәрмәч ята.

— Нигә үзең алмыйсың? — дим.

— Миңа кирәкми,— ди.

Басмага кереп киттем. Уртасыннан уздым. Хәзер иеләсе дә аласы.

— Миңа да уйнап торырга бирерсең,— ди Вакыйф.

Чүгәләдем дә тәгәрмәчкә иелдем. Буй җитми... Ә аста су ага. Каппкара, язгы су.

Булмый икән болай. Таяк алып килергә кирәк. Алып килдем. Сузылдым. Тәгәрмәч эченә таякны кертергә маташам. Ә су шундый тиз ага...

Суга карап, баш әйләнеп киткән икән — ташуга барып төшкәнне сизми дә калганмын.

Агып киттем...

Яр буйлап бер апа йөгерә, балалар чаба. «Авызыңны йом, су кертмә! — ди әлеге апа. Аннары: — Ташка тотын, ташка!» — ди.

Мин нindидер ташка ябышырга өлгерәм. Теге апа, муеныннан суга кереп, мине алып чыга.

Күз кырые белән генә Вакыйфны күреп алам: ул, артына карый-карый, тау буйлап йөгерә...

**Төлке...**

Тау башында, чаңгы таякларына таянып, Вакыйф белән икәү басып торабыз.

— Исмәгыйль абыйлар кичә төлке тоткан,— ди Вакыйф.

— Каян?

— Гөдәвәрдәге әскерт яныннан.

— Ничек тотканнар аны?

— Аны тоту бик җиңел икән: әскерт төбенә барасың да уң ягыңа ятып йоклыйсың. Түлке йоклар алдыннан йөзгә хәтле санарга кирәк, ди. Төлке үзе синең янга килә икән. Шуннан уянасың да тотып аласың, ди.

Көннәрдән бер көнне мин Гөдәвәргә төлке тотарга киттем. Барып җиткәч, чаңгыларны эскерткә сөяп куйдым да, карга салам җәеп, йокларга яттым. Бер, ике, өч, дүрт, биш...

Мине ферма малларына салам алырга килгән Хәбир абый төрткәләп уятты.

Үзем сөйләшә дә алмыйм, әллә нинди авазлар гына чыгарам. Хәбир абый, атны куа-куа, мине больницага алып кайтты. Тәнне спирт белән ышкый-ышкый көчкә хәл керттеләр. «Нишләдең анда?» — диләр.

— Төлке то-то-та-тарга... ба-бардым...

Шуннан соң Хәбир абый мине очраткан саен ерактан ук атын туктатып сорый торган булып китте:

— Ничек соң әле, тотмадыңмы төлкене?

— Юк әле...

### Отряд

— Әйдә, отряд төзибез,— ди Вакыйф.

— Әйдә,— дим мин.

— Әйдә,— ди миннән бәләкәйрәк Фоат.

— Әйдә,— ди Фоаттан да бәләкәйрәк Алмаз.

— Әйдә,— ди иң кечкенә Өлфәт.

— Мин командир булам,— ди Вакыйф.

Беркем каршы килми. Ул безнең арада иң зурыбыз. Мәктәптә укый. Ә безгә ул бәхет кайчан тияр әле?!

— Ипиеңне миңа бир,— ди Вакыйф бал белән май ягылган ипи ашап торучы Өлфәткә. Өлфәт телемне соңгы тапкыр тешли дә Вакыйфка суза. Командирга буйсынмыйча булмый шул!

Вакыйф ипине тиз-тиз генә капкалап йота да боерык бирә:

— Тезелегез!

Вакыйф артыннан мин, минем арттан Фоат, Фоат артыннан Алмаз, Алмаз артыннан Өлфәт баса.

— Киттек минем арттан!

Ялан тәпиләрне кайнар тузанда пешерә-пешерә, ана казга ияргән бәбкәләр шикелле, Вакыйф артыннан теркелдибез. Тагын боерык яңгырый.

— Әйдә, йөгерәбез! Алдан барганда — медаль, артта калганга — канчил койрыгы!

Канчилның ни икәнен берәү дә белми, артта калганга булгач, юньле нәрсә түгеллеген Өлфәткә чаклы аңлый. Дәррәү йөгерә башлыйбыз. Вакыйф үзе артта кала. Яңа боерык ишетелә:

— Артта калганга — медаль, алдан барганга — канчил койрыгы.

Бөтенебез дә шып тукталабыз. Бер урында таптанып тора башлыйбыз. Нишләргә икән? Вакыйф кинәт кенә йөгереп китә:

— Алдан барганга — медаль, артта калганга — канчил койрыгы!

Без Вакыйф артыннан куа китәбез...

Отрядыбыз җәй буе яшәде.

Әмма көз азакларында, чана шуа башлаган көннәрдә...

Бер вакыт үзенең агачтан ясалган зур, иске чанасына бөтен отрядны утырта Вакыйф.

— Үзең дә утыр,— дим мин, чана артында аңа да урын калдырып.

— Мин этеп җибәргәч утырам,— ди ул.

Этеп җибәрә, борылып карыйм,— Вакыйф юк. Чана, киң табаннары белән чыжлап, аска оча. Ә аста — күл. Бозы юп-юка, кичә төнлә генә каткан... Аякларны терәп, туктарга тырышабыз, әмма карт чана барыбер эчкә алып кереп китә. Уртага җиткәч, туктый. Дүртәүләп сикереп торуыбыз була — боз ярыла...

Ярый әле күле тирән түгел. Ал-

мазларның этиләре якында гына бура бурап ята икән — дүртебезне дә күлдән сөйрәп чыгаралар.

Вакыйфны эзлибез — юк Вакыйф. Чанасы, агач башын сузып, күл уртасында бездән ыржаеп көлгәндәй торып кала...

### Трактор

Кич. Ай чыгып килә. Трактор эчендә утырабыз. Вакыйф, Фоат, мин. Фоат туктаусыз «тыр-тыр-тыр» дип тырылдавын белә. Имештер, тракторга утырып, каядыр китеп бара. Вакыйф тегеннән тарта, моннан тарта — нәрсәдер эшли. Мин ишектән башны чыгарып карап торам — Тәлгать абый күренмиме? Бетерә башны, күрсә... Ярый әле тракторын бакча артында калдырган. Урамда булса, монда кереп утыру түгел, яныннан да үтә алмас идең. И, рәхәтлеге шушы күн урындыкта тирбәнә-тирбәнә утыруларның! Май исе, солярка исе шундый тәмле! Дөньяда иң бәхетле кеше — Тәлгать абыйдыр, мөгаен. Шушы күн кабинага кереп утырган килеш, шушы тәмле май исен иснииснп, шушы ялтырап беткән тимерләрне тотып утырулар, шушы тәрәзәдән караулар, шушыны «тыр-тыр» кабызып каядыр китеп барулар — нинди кызык бит! Әйе, әйе, дөньяда иң бәхетле кеше — Тәлгать абыйдыр. Шуңа күрә тракторы янына бүтәннәрне якын җибәрмидер ул.

Тышта чикерткәләр сайрый. Эчтә Фоат тырылдый. «Төшегез, килеп җиттек»,— ди. Төшүче юк. Фоат яңадан тракторын «кабыза» һәм яңадан иреннәре белән трактор йөргән тавыш чыгара башлый. Торган саен катырак тырылдый. «Шаулама әле колак төбендә!» — ди Вакыйф. Ул һаман нәрсәләрнедер тарта, нәрсәләрнедер бора. «Тауга менәбез бит, күрмисеңмени?» — ди Фоат... Тауны мендек, тигез җирдән киттек. Трактор бик хутлы чаба. Бер урында «чигенеп» тә ала әле. Ташмазар булгандыр, күрәсең. «Төшегез, килеп җиттек»,— ди Фоат.

— Нишлисез сез монда, малайлар?!

Чү, кем бу? Тәлгать абый түгелме соң? Кайда Вакыйф? Вакыйф юк!.. Әнә ич — Тәлгать абый артында тора... Фоат белән икебез дә ишеккә ябырылабыз. Әмма ишек ачылмый. Вакыйф аны тыштан тимер чыбык белән әйбәтләп борып куйган. Ә үзе, безгә телен күрсәтеп, көлеп торуын белә...

### Бәбкә саклаганда

Өстә тилгән әйләнә.

Эләктерер иде дә бит безнең бәбкәләрне, алар янында пумала тотып мин утырам шул. Курка, килми тилгән.

Ялыктыра бәбкә саклавы.

Менә бер заман, чыраена бик эшлекле кыяфәт кертеп, балакларын сызганган Вакыйф килеп чыкты.

— Әйдә урманга!

— Әни ачулана. Бәбкә саклыйсы бар.

— Һи-и, минем дә әни ачуланып калды әнә!

— Әнине тыңламасаң, эти кирәкне бирә шул.

— Һи-и, минем эти дә кирәкне бирә ул... Юк, минем эти тилгән оясын туздырганга мактый гына! Без бит урманга тилгән оясын туздырырга барабыз. Тилгән оясын туздырырга кирәк, ди эти. Тилгән бәбкә урлый, ди.

— Без анда киткәч, бәбкәне тилгән алса?

— Һи-и, нишләп алсын ди! Без анда киткәнне күргәч, ул үзе дә мон-

да очып йөрми, оясына кайта. Менә күрерсең!

Урманга барып, тилгән оясын таба алмадык без табуын. Шулай да бер карга оясын туздырдык.

Үч алынды. Кайтырга чыктык. «Барысы да бер иш!» — диде Вакыйф, арттан озата килгән карга чиркенә таяк ыргытып.

«Карга каргышы төшми»,— дигән иде Вакыйф — төшә икән, өйдә әти, мыекларын бик яман боргалап, каеш тотып, мине көтеп утыра иде...

**Учак якканда**

«Моржа»дан төтен күтәрелә.

— Утын алып килегез!

Чыбык-чабык, йомычка алып килеп, Вакыйф алдына ташлыйбыз.

— Коры әрем алып килегез!

Алып килеп алдына өеп куябыз. «Моржа»дан буыла-буыла төтен күтәрелә, ә мич һаман кабынмый.

«Мич» дигәнебез — яр буена чокып ясалган уенты. Өстән тишеп «моржа» үткәрдек. Безнең уебызча, ул бик әйбәт янып китәргә тиеш иде. Кабынмый әле менә. «Шырпы юеш,— ди Вакыйф, төтеннән яшьләнгән күзләрен кыса төшеп.— Кем шырпыга бара?»

— Мин! — дим мин.

— Каян аласың соң син аны?

— Әнидән.

— Әнә генә бит Вәлиханнарның мунчасы,— ди Вакыйф.— Арттан гына керәсе дә аласы. Кеше юк анда.

Вакыйф яңадан мичкә иелә, йөткерә-йөткерә сулышын өрә башлый. Малайлар чаба-чаба әрем ташырга тотыналар.

Вәлиханнарның киртәсеннән сикереп төшәм дә иелә-бөгелә бәрәңге бакчасы буйлап йөгерәм. Каралтыкуралар янына килеп җитәм. Беркем юк. Ишек алдында Нәгыймәттәйнең генә тавышы ишетелә: «Кәҗә!»

Мунчага керәм. Менә — шырпы. Эләктерәм дә атылып ишеккә барам. Абзарлар артыннан йөгерәм һәм... туп-туры Вәлиханның корыч кулына килеп эләгәм.

— Менә кем йөри икән әле монда! — дип кычкыра ул һәм, колагымнан тотып, ишегалдына сөйрәп алып чыга. Ишегалдында Нәгыймә түти кәҗә савып утыра, ләкин безгә әһәмият бирми. Вәлихан мине капка төбенә сөйри. Анда җыен ир-ат җыелышып тәмәке тартып утырган чак икән! Вәлихан мине тегеләрнең алдына бастыра.

— Менә, мунчадан шырпы урлап чыгып килә иде!

Җәлил абый миңа илтифатсыз гына карап ала:

— Ник кердең анда?

— Без... тарлау... тарлауда...

— Ут төртергә кергән! — ди Вәлихан.

— Нигә кычкыртасың шуны, сабый гына бит әле ул! — диде Җәлил абый, Вәлиханга карап.

Колагымны тагын бер тапкыр каты гына борды да:

— Бар, ычкын! — диде Вәлихан.

Торып йөгермәкче булган идем, баш әйләнеп, егылып китә яздым.

— Шырпың кайда? — дип каршылады мине җиргә сузылып яткан Вакыйф.

— Тоттылар.

— Кем тотты?

— Вәлихан.

— Суктымы?

— Юк...

Вакыйф бот чаба-чаба, тәгәри-тәгәри көлә.

— Сугу гына түгел, кара янмаган җиреңне калдырмагандыр әле!

### Җиләктә

— Әйдә, җиләккә барабыз! — ди Вакыйф.

— Әйдә! — ди Фоат.

— Әйдә! — ди Алмаз.

— Әйдә,— ди Өлфәт.

Кайсыбыз стакан, кайсыбыз кружка, кайсыбыз банка тотып, урман юлы буйлап китәбез.

Каен җиләге байтак күренә урманда. Ләкин бу Вакыйфны канәгатьләндерми.

— Унберенчегә барабыз, шунда инде җиләкнең оясы,— ди ул.

Унберенченең кайдалыгын Вакыйфтан кала берәү дә белми. Хәйран баргач икән ул. Урман эчендә киң-киң аланнар бар икән. «Алмазның стаканы белән генә анда берни эшләп булмый»,— ди Вакыйф. Үләне гел юк икән анда, кып-кызыл җиләк кенә икән. «Ярый әле фуражканы алганмын!» — дип сөенеп куйды Алмаз.

Урман. Барабыз, барабыз — юк Унберенче. Биек усаклар. Караңгы. Ниһаять, ачыклык. Монда җиләк түгел, үләне дә берән-сәрән генә күренә. Өлфәт: «Әйдәгез, шушында утырып ял итик»,— ди. Вакыйф әйтә: «Ботинкаңның уңын сулга кигәнгә күрә арасың син»,— ди. Аның сүзенә карап Өлфәт ботинкаларын алыштырып киде. Вакыйф көләргә тотынгач: «Ник бутыйсың кешене, этләй»,— дип, Өлфәт аның өстенә килә башлады. Суга алмаса да, тешли торган гадәте бар аның.

Янәдән бер аланга юлыгабыз. Алмаз, алга таба йөгереп, пешмәгән өч җиләкне стаканына сала. Менә тагын бер ачыклык. Анысында да берничә җир җиләге һәм каен җиләге табып алабыз. «Күп калмады инде барасы»,— ди Вакыйф. Шактый гомер теркелдибез. Аяк асты юешләнә. Бераздан куе агачлык белән әйләндереп алынган пәрәвезле, чит-читләре куе үләнле зур гына күлгә килеп чыгабыз. Бакалары да бар: «ба-ка-ка-ка!» дип безне каршы алалар. Күлне күргәч, Вакыйф та башын кашып, өскә бихисап булып ябырылган озынборыннарны куа-куа, бер мәлгә аптырашка калгандай булды. Әмма бу озакка сузылмады. Кинәт кенә ул: «Куян!» — дип кычкырып, куаклыкка кереп чумды. Күпме эзләсәк тә, куян түгел, Вакыйфның үзен дә таба алмадык. Кире борылдык. Өлфәт, капыл гына җиргә утырып, елый башлады. Без ераграк киткән саен катырак елый. Борылып янына киләбез.

Ничек кайтырга инде хәзер? Юлны беребез дә белми...

### Еллар үткәч

Урам буйлап Вакыйф килә.

— Рәис, малай. Онытмадыңмы әле?

— Нәрсәне?

— Яшь чакларны.

— Ничек итеп урманда адаштырып калдырганыңнымы?

— Ха-ха-ха! Онытмагансың!

— Онытырлык булмады бит. Ярый таптылар икенче көнне.

— Ха-ха-ха! Тәки кеше иттем бит мин сезне, э!

— Иттең.

— Түлке бер дә кәефең юк бугай әле. Чирләмисеңдер бит?

— Юк та. Яз бит. Уң аяк сызлый минем яз көне. Юешне яратмый.

— Э... Нишләп алай икән ул? Зерәгә генә түгелдер, мин әйтәм.

— Зерәгә генә түгел. Төлке тотарга җибәргән идең бит...

— Алай икән... Өлфәт тә чирләп киткән әле.

— Нигә тагын?

— Аның тотлыгуы бар икән... Элек ул нәрсәсе юк иде бугай аның?

— Юк иде... Урманда адашканнан калды.

Ул китә. Мин яшь чакларны искә төшереп калам...